Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

3 март, 2021 ел — № 52

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 1 июнендәге 99 номерлы карары (2018 елның 14 сентябрендәге 160 номерлы, 2020 елның 30 июлендәге 280 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Максатлар, предмет һәм эшчәнлек төрләре» 2 бүлекнең 2.3. өлешендә:

- 2.3.23 пунктында «референдумнары» сүзеннән соң «һәм башкалар» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле 2.3.24 пункт өстәргә:

«2.3.24. Юридик хезмәтләр күрсәтү: Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарына хокукый хезмәт күрсәтү.»;

- 2.3.24 пунктын 2.3.25 пункты дип санарга.

1.2. «Казна учреждениесенең компетенциясе һәм вәкаләтләре» 4 бүлекнең 4.1. өлешендә:

- 4.1.9 пунктында «референдумнар» сүзеннән соң «һәм башкалар» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле 4.1.10 пункт өстәргә:

«4.1.10. юридик хезмәтләр күрсәтергә: Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнарына хокукый хезмәт күрсәтү.».

2. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе

башлыгына Нигезләмәнең билгеләнгән тәртиптә үзгәртелүен дәүләт теркәвенә алганда мөрәҗәгать итүче булырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов